МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ
И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН
ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ
ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

09.07.2015 № 461

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2015 елның 7 августында теркәлде, № 2833

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү
һәм социаль яклау министрлыгының
“Торакка һәм коммуналь хезмәтләр
күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама
билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентын раслау турында”
19.11.2014, № 634 боерыгы белән расланган
Торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә
түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

1995 елның 12 гыйнварындагы “Ветераннар турында” № 5-ФЗ Федераль законга һәм “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 02.11.2010, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының “Торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 19.11.2014, № 634 боерыгы белән расланган Торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пункттагы 1 пунктчасының алтынчы абзацында “1944 елның февраленнән” сүзләрен “1941 елның 22 июненнән” сүзләренә алмаштырырга;

1.2 пункттагы 3 пунктчасының сигезенче абзацында “1944 елның 1 февраленнән” сүзләрен “1941 елның 22 июненнән” сүзләренә алмаштырырга;

1.4.2 пункттагы 1 пунктчасын “Үзәк бүлекләрендә” сүзләреннән соң “. Мәгълүмат стендларына урнаштырыла торган мәгълүмат дәүләт хезмәте турында бу Регламентның 1.1, 1.4.1, 1.5, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган белешмәләрне үз эченә ала” дигән сүзләр белән тулыландырырга;

1.5 пунктның егерме беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

““Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 02.11.2010, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе (алга таба – № 880 Тәртип) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);”;

1.6 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

“Бу Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә) кертелгән мәгълүматларның мәгълүмат керткәндә нигез булып торган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнеңерактагы эш урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә документларны кабул итү һәм бирү, гариза бирүчеләргә консультацияләр үткәрү “тәрәзә”се.”;

“Стандартка таләпләрнең эчтәлеге” графасында 2.6 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“дәүләт хезмәте алучы балигъ булмаган зат булып торган очракта, законлы вәкиленең вәкаләтләрен раслау өчен, 2013 елның 23 октябреннән соң туган балаларның тууын дәүләт теркәвенә алу турында (ЗАГС органнарыннан)”;

2.15 пунктта:

“Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы” графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2.15. Дәүләт хезмәтенең мөмкинлек һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән аралашулары саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәтен дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле

үзәктә, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүматны алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып";

"Стандартына таләпләрнең эчтәлеге" графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып торалар:

документларны кабул итү һәм карап тикшерү сроклары үтәлү;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу срогы үтәлү;

Үзәк бүлеге белгечләре тарафыннан Регламент бозылу очракларының (нигезле шикаятьләрнең) булу-булмавы;

гариза бирүчеләрнең Үзәк бүлеге белгечләре белән аралашуы саны:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар биргәндә, турыдан-туры – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча), ә гариза бирүче билгеләнгән тәртиптә расланган барлык кирәкле документларны тапшырган очракта, аралашу зарурлыгы юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинет аша җибәргәндә:

әгәр гариза һәм документлар күчермәләре № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләренә туры китереп электрон имза куелган (расланган) электрон документлар рәвешендә җибәрелсә, турыдан-туры аралашу таләп ителми;

әгәр гариза һәм документлар күчермәләре № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләренә туры китереп электрон имза куелмаган (расланмаган) электрон документлар рәвешендә җибәрелсә – бердән артык түгел.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлек күрсәткечләре булып торалар:

бүлек биналарының җәмәгать транспорты йөри торган зонада урнашкан булуы;

белгечләрнең кирәкле санда булуы, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган бүлмәләрнең кирәкле санда булуы;

мәгълүмат стендларында, "Интернет" челтәрендә, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының рәсми сайтында хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе, сроклары турында тулы мәгълүматның булуы;

гаризаны электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге;

электрон документлар рәвешендәге гариза һәм документларны Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша тапшырганда, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен гариза бирүченең, электрон рәвештә, Татарстан Республикасы Дәүләт

хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинеты аша алу мөмкинлеге.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, гариза бирүченең Үзәк бүлеге белгече белән бер тапкыр аралашуының дәвамлылыгы 15 минуттан артык түгел.

Дәүләт хезмәте (дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп) күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең ерактагы эш урыннары аша күрсәтелми.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүматны гариза бирүче http://mtsz.tatarstan.ru сайтыннан, Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрне бердәм порталыннан алырга мөмкин.";

"Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгеләүче норматив акт" графасында "№ 880 ТР МК карары" сүзләрен "№ 880 Тәртипнең" сүзләренә алмаштырырга;

"Стандартка таләпләрнең эчтәлеге" графасында 2.16 пунктның дүртенче абзацын төшереп калдырырга;

3 бүлекнең атамасын "күпфункцияле үзәкләрдә" сүзләреннән соң ", дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең ерактагы эш урыннарында" сүзләре белән тулыландырырга;

3.2.1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Үзәк бүлеге белгече, гариза бирүченең мөрәҗәгать итү ысулына бәйле рәвештә, шәхсән үзе, телефоннан, электрон почта аша һәм (яки) хат белән, мөрәҗәгать итүчегә консультация бирә, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге ягыннан һәм гариза бирүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.";

3.3.2.2 пунктта өченче абзацны төшереп калдырырга;

3.4.2.2 пунктта икенче абзацны төшереп калдырырга;

3.5 пунктны "күпфункцияле үзәк" сүзләреннән соң "һәм дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең ерактагы эш урыннары" сүзләре белән тулыландырырга;

Регламентны түбәндәге эчтәлекле пунктлар белән тулыландырырга:

"3.6. Техник хаталарны төзәтү

Субсидия-ташлама билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карарны үзгәртеп рәсмиләштерү субсидия-ташлама билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында элегрәк кабул ителгән карарда җибәрелгән техник хаталарны (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хата) бетерүгә бәйле рәвештә башкарыла.

Субсидия-ташлама билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карарны үзгәртеп рәсмиләштерү гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән техник хаталы документ өстәлгән теркәлгән гариза (бу Регламентка 6 нчы кушымта) нигезендә башкарыла.

3.6.1. Үзәк бүлеге белгече:

техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында (3 нче кушымта) терки;

субсидия-ташлама билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар проектын үзгәртеп рәсмиләштерә;

субсидия-ташлама билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар проектын Үзәк бүлеге җитәкчесенә имза куюга җибәрә.

Бу пункт билгели торган процедуралар гариза теркәлгән моменттан башлап бер көн эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турындагы кабул ителгән, теркәлгән гариза, субсидия-ташлама билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән, Үзәк бүлеге җитәкчесенә имза куюга җибәрелгән карар проекты.

3.6.2. Үзәк бүлеге җитәкчесе субсидия-ташлама билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны имзалый һәм Үзәк бүлеге белгеченә җибәрә.

Бу пункт билгели торган процедура субсидия-ташлама билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән проекты имза куюга җибәрелгән моменттан бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: субсидия-ташлама билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән  имзаланган карар.

3.6.3. Үзәк бүлеге белгече субсидия-ташлама билгеләү (билгеләүдән баш тарту)  турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны, гаризада күрсәтелгән ысул белән, гариза бирүчегә хәбәр итә.

Бу пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланган моменттан бер көн эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: субсидия-ташлама билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар хакында гариза бирүчегә хәбәр итү.";


5 бүлекнең атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5. Гариза бирүче тарафыннан Үзәкнең дәүләт хезмәте күрсәтүче бүлегенең, шулай ук аның вазыйфаи затларының һәм хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата  судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерелү тәртибе".

Регламентка 4 нче һәм 5 нче кушымталарны кушымта итеп бирелүче яңа редакциядә бәян итәргә:


"Торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

# Гариза бирүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә яисә гариза документларны почта аша җибәргәндә, торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы



Торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

## Гариза бирүче Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы



Субсидия-ташлама бирү (бирүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны гариза бирүчегә житкерә – 1 көн → ” Субсидия-ташлама бирү (бирүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар

Регламентны түбәндәге эчтәлекле 6 нчы кушымта белән тулыландырырга:

“Торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
6 нчы кушымта

РЦМП (КВ) №____ бүлеге
____________________________
муниципаль райондагы (шәһәрдәге)

Техник хатаны төзәтү турында
гариза

Мин,__________________________________________________________________________,
(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча күрсәтелә)
түбәндәге адрес буенча яшим:
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
(индексын күрсәтеп, гариза бирүченең почта адресы, телефоны, электрон адресы)
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
(гариза бирүченең шәхесен таныклаучы документ атамасы, аның сериясе, номеры, бирү көне, документны биргән орган атамасы)

Социаль ярдәм чараларын билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы
_______________ № _______________
(карар датасы) (карар номеры)
карарда җибәрелгән техник хатаны ______________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
төзәтүне үтенәм.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны __________________________________ алырга риза.
(язмача, электрон почта белән, ТР Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетка)

“__” _________ 20__ ел _______________ ______________________________
(гариза бирүче имзасы) (тулы имза)”.

**Министр** **Э.Ә.Зарипова**